ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

____13.08.2018_____ Казан ш. № ___64_____

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 21 статьясы нигезендә

**Б О Е Р Ы К  Б И Р Ә М:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Билгеләргә:

гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлеге һәм Хокук идарәсе катнашында гамәлгә ашырыла;

гражданнарның коррупциячел юнәлешле фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар хезмәт мәгълүматының һәм конфиденциаль холыклы белешмәләрнең саклануы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык — В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелеш күзәтчелеге инспекциясе
башлыгының 2018 елның 13.08.2018
№ 64
боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә (алга таба – Инспекция) килгән, коррупция һәм янау, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт хәленнән явызларча файдалану билгеләре булган, Инспекциядә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны биләүче, Инспекция эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче һәм хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан башка төрле гамәлләрне кылу фактлары турында белешмәләрне үз эченә ала торган коррупциячел юнәлешле фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен (алга таба – мөрәҗәгатьләр) карау үзенчәлекләрен билгели.

Бүтән затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә карый торган тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Гражданинның коррупциячел юнәлешле фактлар буенча мөрәҗәгате (алга таба – мөрәҗәгать) «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

3. Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында теркәлгәннән соң, мөрәҗәгать дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлегенә һәм Инспекциядә коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрелә.

Килгән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки

кылган зат турында белешмәләр булса, мондый мөрәҗәгать компетенцияләренә ярашлы рәвештә хокук саклау органнарына җибәрелә.

4. Билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүен уздыру инициативасы белдерелә (хезмәткәрдән язмача аңлатмалар таләп ителә).

5. Хезмәт тикшерүен уздырган комиссия бәяләмәсе нигезендә коррупциячел күренеш билгеләре булуы турында мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, башлык (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә йогынты актын кертә. Язмача аңлатмаларын анализлаудан чыгып, хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланган очракта, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Әгәр хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнеп ятучы, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылган яки кылган зат турында мәгълүм булса, тиешле мәгълүмат, компетенцияләренә туры китереп, хокук саклау органнарына юлланырга тиеш.

6. Мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга җавап әзерләү җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлеге, шулай ук Хокук идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша җаваплы затка гражданинга җавап җибәрү срогы тәмамланганчыга кадәр кимендә 15 көн алдан мөрәҗәгать буенча язмача тәкъдимнәр җибәрелә.

7. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупциячел юнәлешле фактлар турында белешмәләр булса, соңгысы үз-үзен кире кагып, аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлеге, шулай ук Хокук идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Дәүләт хезмәткәрләрен дисциплинар җаваплылыкка тарту «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законда, хезмәткәрләрне – Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алу җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Ел саен, хисап елыннан соң килгән елның 1 февраленә кадәр, җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгатьләр гомумиләштерелә һәм анализлана, алар нәтиҗәсендә

җаваплы зат мөрәҗәгатьләрне карау буенча эш нәтиҗәләре һәм күрелгән, шул исәптән профилактик холыклы, чаралар турында белешмә төзи һәм Инспекция башлыгына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә.